СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д.10,
с. Татарское Утяшкино,423186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы,423186

тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65, Ut.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге Советы

# КАРАРЫ

2023 елның «17» мартыннан № 32-114

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлеге Советының 12.07.2022 ел 24-83 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсәавыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының 12.07.2022 ел 24-83 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (30.12.2022 ел, № 30-105 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 6 статьясындагы 1 өлешенең 4 абзацында «ким дигәндә бер һәм өч айдан артык түгел» сүзләрен «бер айдан артык түгел» дип алыштырырга;

1.2. 4 бүлекнең 14 статьясындагы 5 өлешендә «бер айдан да ким булмаган һәм өч айдан да артмаган» сүзләрен «бер айдан да артмаска тиеш» дип алыштырырга;

1.3. 16 статьяның 3 өлешендә 4 бүлек «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн яки утыз көннән артык» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.И.Назмутдинова